**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ**

# КАРАР

14.03.2016 № 21

**2016 елның 13 мартында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьясы нигезендә, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе **2016 елның 13 мартында** узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде:

«2016 елда Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертү (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, Бөек Ватан сугышы ветераннары, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен) 1әм акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - юлларга вак таш салу: | |
| | | Иске Кырлай авылы, | 21400 сум |
| | | ИскеИябаш авылы | 20900сум |
| | | Өтнә авылы | 9400сум |
| | | Югары Әзәк авылы | 12700сум |
| | | Түбән Мәтәскә авылы | 63000сум |
| | | Югары Мәтәскә авылы | 37200сум |
| | | Мөндеш авылы | 60400сум |
| | | Казиле авылы | 20100сум |
| 2 | Күмү урыннарын карап тоту | -зират коймаларын урнаштыру һәм карап тоту: | |
| | | Иске Кырлай авылы | 12000сум |
| 3 | Төзекләндерүне оештыру | светильникларны алыштыру һәм урнаштыру: | |
| | | Иске Иябаш авылы | 3000сум |
| | | Өтнә авылы | 1000сум |
| | | Барлыгы: | 261100 сум |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә".

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 1632 референдумда катнашучы кертелгән;

референдумда катнашучылар саны 1463, бу 89,64 процент тәшкил итә;

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 1380 кеше тавыш бирде, бу 94,33 процент тәшкил итә;

«юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 83 кеше тавыш бирде, бу 5,67 процент тәшкил итә.

Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча районы Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган дип танырга, ә референдум нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә:

«2016 елда Иске Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертү (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, Бөек Ватан сугышы ветераннары, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен) һәм акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - юлларга вак таш салу: | |
| | | Иске Кырлай авылы, | 21400 сум |
| | | ИскеИябаш авылы | 20900сум |
| | | Өтнә авылы | 9400сум |
| | | Югары Өзәк авылы | 12700сум |
| | | Түбән Мәтәскә авылы | 63000сум |
| | | Югары Мәтәскә авылы | 37200сум |
| | | Мөндеш авылы | 60400сум |
| | | Казиле авылы | 20100сум |
| 2 | Күмү урыннарын карап тоту | -зират коймаларын урнаштыру һәм карап тоту: | |
| | | Иске Кырлай авылы | 12000сум |
| 3 | Төзекләндерүне оештыру | светильникларны алыштыру һәм урнаштыру: | |
| | | Иске Иябаш авылы | 3000сум |
| | | Өтнә авылы | 1000сум |
| | | Барлыгы: | 261100 сум |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә".

3. Җирле референдумның гомуми нәтиҗәләрен Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б.И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л.И. Нурмиева